# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Саклаубаш авыл җирлегенең Өчиле Саклау торак пунктында
2024 елда үзара салым кертү турында

**2023 нче елның 17 нче ноябре** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Саклаубаш авыл җирлегенең Өчиле Саклау авылында гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. 2024 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Саклаубаш авыл җирлеге Өчиле Саклау авылы территориясендә I төркем инвалидлардан; хәрби хезмәт үтүчеләрдән; көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча Өчиле Саклау авылында теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өсен түбәндәге эшләрне башкарырга җибәрергә:
1) Өчиле Саклау торак пунктына урам яктырту челтәрләрен ясау.
2) Төзелеш материаллары сатып алу һәм су башнясына койма тоту
3) автомобиль юлларын карап тору өчен МТЗ-82.1 махсус техникасын карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запчастьләр сатып алу, машина йөртүчегә хезмәт хакы түләү);
4) Халыкара хатын-кызлар көне, Җиңү көне, сабантуй, өлкәннәр көне, Инвалидлар көне, Өчиле-Саклау торак пунктында төрле чаралар үткәрү өчен бүләкләр, алу;

3. Әлеге карарны Саклаубаш авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Сарман муниципаль районы
Саклаубаш авыл җирлеге башлыгы,
гражданнар җыенында рәислек итүче Л.М.Габидуллина